ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТОЙГУҖА
ТОРАК ПУНКТЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

---

КАРАР

«20» ноябрь 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Тойгуҗа авыл
җирлегенең Тойгуҗа торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 10 ноябрендәге 1 нче номерлы карары нигезендә 2025 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыенында “2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертергә, Россия Армиясе сафларына срокты хәрби хезмәткә чакырылган, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентларны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?” дигән сорау каралды һәм беркетмә төзелде.

1. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Тойгуҗа авылында 2 (ике) данә янгын гидранты сатып алу);
2. Урамнарны яктырту җайланмасы: (урамнарны яктырту диодлы яктырткычлар сатып алу);
3. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү: (Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә үлән чабу өчен бензин белән эшләүче триммер сатып алу; Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә үлән чабу);
4. Узган еллардан калган үзара салым акчаларын Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә печән чабуга җибәрергә?

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
- гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 109 катнашучы кертелде;
- гражданнар җыенында тавыш бирүдә 63 кеше катнашты.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
- «ӘЙЕ» позициясе өчен 63 граждан тавыш бирде;
- «КАРШЫ» позициясе өчен 0 тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:
1. Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танылырга.
2. “2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертергә, Россия Армиясе сафларына сроклы хәрби хезмәткә чакырылган, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентларны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?” дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

1. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Тойгуҗа авылында 2 (ике) данә янгын гидранты сатып алу);
2. Урамнарны яктырту җайланмасы: (урамнарны яктырту диодлы яктырткычлар сатып алу);
3. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү: (Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә үлән чабу өчен бензин белән эшләүче триммер сатып алу; Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә үлән чабу);
4. Узган еллардан калган үзара салым акчаларын Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә печән чабуга җибәрергә?

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Тойгуҗа авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сафин